**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 27 августындагы 3589 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 29 августындагы 4744 номерлы «Казан шәһәренең физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 129 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 15 августындагы 671 номерлы «Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарын (аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 15 апрелендәге 290 номерлы, 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы, 2022 елның 20 июнендәге 587 номерлы, 2022 елның 14 сентябрендәге 1002 номерлы, 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы, 2024 елның 19 июнендәге 442 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үтәү йөзеннән **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 29 августындагы 4744 номерлы «Казан шәһәренең физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 маендагы 1363 номерлы, 2023 елның 8 июнендәге 1592 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы, 2 номерлы кушымталарны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның 1 номерлы, 2 номерлы кушымталарын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 29 августындагы 4744 номерлы карарының 1 номерлы, 2 номерлы кушымталары дип санарга.

2. Әлеге карарның йогынтысы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 27 августындагы
3589 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәренең муниципаль физик культура
һәм спорт учреждениеләре
хезмәткәрләренең хезмәте өчен
түләү шартлары турында
нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Казан шәһәренең муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәре окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын гамәлгә кертә.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – төп (вазифаи) окладлар күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне кертеп, муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесенең тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы хезмәткәренең компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре исәпкә алынмаган оклады;

- вазифаи оклад – муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе хезмәткәре хезмәтенә, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, бер календарь ай эчендә фактта эшләгән вакытта билгеле бер авырлыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен түләүнең билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәт өчен түләү) – хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына бәйле рәвештә хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре;

- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы, шул исәптән нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

- стимуллаштыру характерындагы түләүләр – стимуллаштыру характерындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, авыл хуҗалыгы вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба тәртип буенча – физик культура хезмәткәрләре, мәгариф хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре) хезмәт хакы (хезмәт өчен түләү) түбәндәгеләреннән чыгып билгеләнә:

- вазифаи окладлардан;

- стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

- компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеэсе хезмәткәренең еллык яисә башка ялда булу вакытында, аның вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук аның уртача хезмәт хакы сакланып кала торган башка чорларда профиль буенча эш стажы артуга, белем алуга яисә белем алу турындагы документларны торгызуга, квалификация категориясе бирелүгә, дәүләт бүләге бирелүгә, ведомствоның аерым хөрмәт билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә хезмәтенә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килгәндә, аның хезмәтенә түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

1.5. Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчеләре:

- белеме һәм эш стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазифадагы эш) турында документларны һәм муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерәләр;

- ел саен муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

- муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап тоталар.

## II. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча төп окладларын билгеләү

2.1. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча төп окладлар түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Спорт залы буенча дежур | 19 242 |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Адаптив физик культура буенча инструктор | 20 105 |
| | Спорт инструкторы | |
| | Спортчы-инструктор | |
| | Спорт техникасыннан файдалану һәм аны ремонтлау буенча техник | |
| Икенче | Адаптив физик культура буенча инструктор-методист | 20 112 |
| | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты | |
| | Тренер | |

| | | |
|---|---|---|
| Өченче | Физкультура-спорт оешмаларының өлкән инструктор-методисты | 20 118 |

2.2. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча төп окладлар түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Физик культура буенча инструктор | 20 705 |
| Икенче | Инструктор-методист | 20 800 |
| Өченче | Методист | 20 900 |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Структур бүлекчә мөдире (башлыгы): кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм балаларга гомуми белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчәләр (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләреннән тыш) | 21 050 |
| Икенче | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 21 100 |

2.3. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча төп окладлар түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче | Шәфкать туташы (медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 21 163 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина хезмәткәре (ир-ат)) | |
| Бишенче | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медицина хезмәткәре (ир-ат)) <*> | 22 863 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 24 563 |
| «Учреждениеләргә караган структур бүлекчәләрнең югары медицина һәм фармацевтика белеме булган җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор)» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Структур бүлекчә (бүлек, бүлекчә, лаборатория, кабинет, отряд һ.б.) мөдире (стационарларның хирургия профиле бүлекләре мөдирләреннән тыш) | 27 363 |

<*> Вазифа оешмада кул астында өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташы булган очракта билгеләнә.

2.4. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләрендәге мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча төп окладлар түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Билетлар контролеры | 20 531 |
| «Урта звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |

| | |
|---|---|
| | |
| Билет кассалары мөдире | 20 862 |

2.5. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләрендәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча төп окладлар түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| «Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифасы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Ветеринария табибы | 20 868 |
| Икенче | II категорияле ветеринария табибы | 20 923 |
| Өченче | I категорияле ветеринария табибы | 20 978 |
| Дүртенче | Әйдәүче ветеринария табибы | 21 033 |
| «Дүртенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифасы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Баш агроном | 22 265 |

## III. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең төп окладлы өчен сәгатьләр нормасы

Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

## IV. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре тренерлары хезмәтенә бер шөгыльләнүче өчен билгеләнгән түләү нормативлары

4.1. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең физкультура-сәламәтләндерү төркемнәренең һәм спорт секцияләренең тренеры

хезмәтенә түләү нормативы бер шөгыльләнүче өчен 2 процентка тигез дип кабул ителә.

4.2. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең физкультура-сәламәтләндерү төркемнәренең һәм спорт секцияләренең тренеры хезмәтенә түләү нормативы әлеге төркемнәрдә (секцияләрдә) бер тренерда шөгыльләнүнең һәр ике елы саен 0,5 процентка арта.

## V. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

5.1. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре тренерының вазифаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \sum_{i=1}^{n} N_i ,$$

биредә:

$O_b$ – хезмәткәрләрнең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган нигез окладының күләме;

Ni –муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре тренерының бер шөгыльләнүче өчен хезмәтенә әлеге Нигезләмәнең IV бүлеге нигезендә кабул ителә торган түләү нормативлары.

5.2. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең вазифаи окладлы ($O_d$) (вазифаи окладлы әлеге Нигезләмәнең V бүлегендәге 5.1 пункты нигезендә исәпләнә торган тренердан тыш) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \text{ x } S,$$

биредә:

$O_b$ – муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп окладлы күләме;

S – муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре били торган ставкаларның факттагы саны.

## VI. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

6.1. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрен хезмәтнең сыйфат нәтиҗәсенә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр стимуллаштыру характерындагы түләүләргә керә.

6.2. Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- квалификация категориясе өчен түләүләр;
- мактаулы исемнәр, спорт исемнәре булган өчен түләүләр;
- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;
- башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

6.3. Физик культура хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм тәртибе.

6.3.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) физик культура хезмәткәрләренә, гамәлдәге квалификация категориясе булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – физик культура хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ – 1 таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

1 таблица

**Физик культура хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| | Беренче квалификация категориясе | 2,5 |

| | | |
|---|---|---|
| Беренче | Югары квалификация категориясе | 3,0 |
| Икенче | Беренче квалификация категориясе | 3,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 4,3 |
| Өченче | Беренче квалификация категориясе | 3,8 |
| | Югары квалификация категориясе | 5,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләр тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән билгеләнә (үзгәртелә).

6.3.2. Мактаулы исемнәр, спорт исемнәре ($B_{pz}$) булган өчен түләүләр физик культура хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр, спорт исемнәре өчен өстәмәләр күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Физик культура хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирү өчен нигез булып торган дәүләт бүләкләре, спорт дәрәҗәләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасындагы 4 таблицада китерелгән.

Мактаулы исемнәр, спорт исемнәре булган өчен түләүләр күләме мактаулы исем, спорт исеме бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исеме, ике һәм аннан күбрәк спорт исеме булган физик культура хезмәткәрләренә мондый исемнәр булган өчен бирелә торган түләү, физик культура хезмәткәре теләгенә нигезләнеп, берсе буенча билгеләнә.

6.3.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), профиль буенча эшләү дәвамлылыгына бәйле рәвештә, төркемнәрдән, һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләреннән чыгып, стаж буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – физик культура хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – 2 таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

2 таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме атамасы** | **Квалификация дәрәҗәсе** | **Стаж буенча төркем** | **Өстәмә түләүләр күләме, процент** |
|---|---|---|---|
| Физик культура хезмәткәрләренең беренче дәрәҗәдә вазифалары | Беренче-икенче | 2 елдан 5 елга кадәр | 1,25 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 1,75 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,25 |
| | | 15 елдан артык | 2,75 |
| Физик культура хезмәткәрләренең икенче дәрәҗәдә вазифалары | Беренче – өченче | 2 елдан 5 елга кадәр | 1,25 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 1,75 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,25 |
| | | 15 елдан артык | 2,75 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесендә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

6.4. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме һәм тәртибе.

6.4.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) физик культура хезмәткәрләренә, гамәлдәге квалификация категориясе булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ – 3 таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

3 таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 5,0 |
| | Югары | 7,5 |
| Икенче | Беренче | 7,5 |
| | Югары | 10,0 |
| Өченче | Беренче | 8,5 |
| | Югары | 12,5 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 10,0 |
| | Югары | 15,0 |
| Икенче | Беренче | 10,0 |
| | Югары | 15,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләр тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән билгеләнә (үзгәртелә).

6.4.2. Мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләү ($B_{pz}$) мәгариф хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм ведомство бүләкләре өчен өстәмәләр күләме.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең ведомство бүләкләре, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре, Советлар Социалистик Республикасы Союзының ведомство бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Мактау грамотасы булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясенең Мактау грамотасы булган өчен өстәмә түләү Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе мәгариф министры) әмере белән бүләкләнүче мәгариф хезмәткәрләренә билгеләнә.

Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) әмере нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр түләнә торган дәүләт һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасындагы 1 таблицада китерелгән.

Мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм ведомство бүләкләре бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исеме, ике һәм аннан күбрәк спорт исеме булган, ике һәм аннан күбрәк ведомство бүләкләре бирелгән мәгариф хезмәткәрләренә, мондый исемнәр һәм бүләкләр булган өчен бирелә торган түләү, мәгариф хезмәткәре теләгенщ нигезләнеп, мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм ведомство бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

6.4.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), профиль буенча эшләү дәвамлылыгына бәйле рәвештә, төркемнәрдән, һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләреннән чыгып, стаж буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – 4 таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

4 таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме атамасы** | **Квалификация дәрәҗәсе** | **Стаж буенча төркем** | **Өстәмә түләүләр күләме, процент** |
|---|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазифалары | Беренче – дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 1,5 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,25 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,75 |
| | | 15 елдан артык | 3,25 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифалары | Беренче – икенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 1,5 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,25 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,75 |
| | | 15 елдан артык | 3,25 |

Эш стажы үзгәргәндә, профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар учреждениедә булса, эш

стажы өчен түләүләр күләмен арттырырга хокук бирүче стажны тутырган көннән алып яки стажны раслаучы кирәкле документны тапшырган көннән алып башкарыла.

6.4.4. 5 таблица нигезендә мәгариф һәм башка оешмалардагы педагогик, җитәкче һәм методик эш педагогик эш стажына исәпләнә.

5 таблица

**Эшләгән вакыт мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына кертелә торган учреждениеләр, оешмалар һәм вазифалар исемлеге**

| Оешманың исеме | Вазифа атамасы |
|---|---|
| Мәгариф оешмалары (шул исәптән югары белем бирү мәгариф оешмалары, югары белем бирү хәрби мәгариф оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, белгечләргә өстәмә һөнәри белем бирү (квалификация күтәрү) оешмалары)<br>медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йортлары, балалар шифаханәләре, клиникалары, поликлиникалары, хастаханәләре һ.б. | Мәктәп укытучылары, укытучылар, дефектолог укытучылар, логопед укытучылар (логопедлар), оештыручы-укытучылар (тормыш иминлеге нигезләрен, чакырылышка кадәрге әзерлекне), физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, җитештерү буенча укыту мастерлары (шул исәптән транспорт чараларын йөртергә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә, язу машинкаларында эшләргә һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтә торган), өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар, өлкән вожатыйлар (пионервожатыйлар), физкультура буенча инструкторлар, хезмәт буенча инструкторлар, директорлар (башлыклар, мөдирләр), укыту, укыту-тәрбия, укыту-җитештерү, тәрбия, мәдәни-тәрбия эшләре, сәнәгать буенча укыту (эш), чит телләр укыту буенча, очуга әзерлеккә укыту буенча, гомуми белем бирүгә әзерлек, режим буенча директор (башлык, мөдир) урынбасарлары, укыту буенча мөдирләр, эшчәнлекләре белем (тәрбия) бирү, методик тәэмин итү процессы белән бәйле практика, укыту-консультация пунктлары, |

| Оешманың исеме | Вазифа атамасы |
|---|---|
| | логопедия пунктлары, интернатлар, бүлекчәләр, бүлекләр, лабораторияләр, кабинетлар секцияләр, филиаллар, курслар һәм башка структур бүлекчәләр мөдирләре (башлыклары); режим буенча өлкән дежурныйлар, режим буенча дежурныйлар, аккомпаниаторлар, культоештыручылар, экскурсоводлар; профессор-укытучылар составлары |
| Барлык исемнәрдәге методик (укыту-методик) оешмалар (ведомство карамагында булуына бәйсез рәвештә) | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, секторлар, кабинетлар, лабораторияләр, бүлекләр мөдирләре; эшчәнлекләре методик тәэмин итүгә бәйле фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| Мәгариф белән идарә итү органнары һәм мәгариф оешмалары җитәкчелеген гамәлгә ашыручы органнар (структур бүлекчәләр) | Җитәкчеләр, инспектор, методик вазифалар, инструкторлык, шулай ук белгечләрнең башка вазифалары (икътисади, финанс, хуҗалык эшчәнлеге, төзелеш, тәэмин итү, эш башкару белән бәйле вазифаларда эшләүдән тыш) |
| Җитештерүдә кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, республика башкарма хакимият органнары бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре, техник белем бирү бүлекләре (бюросы) | Эшчәнлекләре әзерлек һәм квалификация күтәрү мәсьәләләре белән бәйле штаттагы укытучылар, сәнәгатьтә эшчеләрне производствога укыту мастерлары, җитәкче, инспектор, инженер, методик вазифалар |
| Россия оборона спорт-техник оешмасы (Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм итүнең иректе җәмгыяте) һәм гражданнар авиациясе мәгариф оешмалары | Җитәкче, команда-очыш, команда-инструкторлык, инженер-инструкторлык, инструкторлык һәм укытучылар составлары, җитештерүгә өйрәтү мастерлары, инженер-инструктор-методистлар, инженер-очучы-методистлар |
| Учреждениеләрнең, предприятиеләрнең һәм оешмаларның тулай тораклары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь тамашачы театрлары, курчак театрлары, мәдәни-белем бирү оешмалары һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү предприятиеләренең һәм оешмаларының бүлекчәләре | Тәрбиячеләр, педагог-оештыручылар, педагог-психологлар (психологлар), укытучылар, балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирү педагоглары (түгәрәкләр җитәкчеләре), балалар һәм яшүсмерләр белән эшли торган инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар һәм башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлары мөдирләре |

| Оешманың исеме | Вазифа атамасы |
|---|---|
| Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү изоляторлары һәм төрмәләр, дәвалау-төзәтү оешмалары | Педагогик белеме булган очракта, түбәндәге вазифаларда эшләү (хезмәт итү): тәрбия эшләре буенча җитәкче урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү (укыту) буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, җитештерү-техник белем бирү буенча өлкән инженер һәм инженер, җитештерү буенча өлкән мастер һәм мастер, саклау һәм режим буенча өлкән инспектор, укыту-техник кабинет мөдире, психолог |

Искәрмә:

Педагогик эш стажына түбәндәгеләр керә:

1) өлкәннәргә социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмаларда һәм медицина оешмаларында укытучы-дефектологлар, логопедлар, тәрбиячеләр, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының оештыру-методик бүлеге методистлары сыйфатында эшләү вакыты;

2) башка учреждениеләрдә һәм оешмаларда эшләү, Совет Социалистик Республикалар Союзы Кораллы Көчләрендә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, югары белем бирү мәгариф оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында түбәндәге тәртиптә уку вакыты:

а) педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына бернинди шартларсыз һәм чикләүләрсез кушыла:

- контракт буенча хәрби хезмәттә булу вакытында – хәрби хезмәттәге бер көн бер эш көне булып, ә чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакыты хәрби хезмәттәге бер көн ике эш көне булып исәпләнә;

- фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазифасында эшләү вакыты;

б) педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына, аерым алганда да, тулаем алганда да әлеге чорлар алдыннан һәм алардан соң педагогик эшчәнлек алып барылган очракта, түбәндәге вакыт чорлары керә:

- контракт буенча һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакытыннан тыш, Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицер, сержант, старшина составларның, прапорщик һәм мичман вазифаларында (шул исәптән Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрендә, куркынычсызлык гаскәрләрендә һәм органнарында) хезмәт итү вакыты;

- Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре (белем бирү, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) профсоюзының территориаль оешмалары

(комитетлары, советлары) аппаратларында җитәкче, инспектор, инструктор һәм башка белгечлек вазифаларында; профсоюз органнарында сайлап куела торган вазифаларда; Балалар фондының педагогик җәмгыятьләрендә һәм идарәләрендә инструктор һәм методист вазифаларында; Укытучы йорты директоры (мөдире) (халык мәгарифе, һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре) вазифасында; балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре яки балигъ булмаганнарны социаль-хокукый саклау бүлекләрендә, эчке эшләр органнарының хокук бозуларны кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекцияләрдә, милициянең балалар бүлмәләрендә) эшләү вакыты.

6.4.5. Педагогик хезмәткәрләрнең түбәндәге категорияләренең педагогик эш стажына белем бирү оешмасындагы эш профиленә яки укыту предметы (курс, дисциплина, түгәрәк) профиленә туры килә торган белгечлек (һөнәр) буенча оешмаларда эшләү вакыты һәм СССР һәм Россия Федерациясенең Кораллы Көчләрендә хезмәт итү вакыты керә:

- тормыш иминлеге нигезләре, чакырылышка кадәрге әзерлек укытучылары-оештыручылар;

- физик тәрбия буенча мәктәп укытучылары һәм укытучылар, физик тәрбия җитәкчеләре, физкультура инструкторлары, инструктор-методистлар (өлкән инструктор-методистлар), тренер-укытучылар (өлкән тренерлар-укытучылар);

- хезмәткә (һөнәри) өйрәтү, технология, сызым, рәсем сәнгате, информатика, махсус дисциплиналар, шул исәптән аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче гомуми белем бирү оешмаларының (сыйныфларының) махсус дисциплиналары укытучылары, мәктәп укытучылары;

- җитештерү белем бирү осталары;

- өстәмә белем бирү педагоглары;

- эксперименталь белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре;

- педагог-психологлар;

- методистлар;

- урта һөнәри белем бирү оешмаларының мәдәният һәм сәнгать, музыкаль-педагогик, сәнгать-график, музыкаль (бүлекләренең) урта бүлек белгечләрен әзерләү программалары буенча педагогик хезмәткәрләре;

- балаларга өстәмә белем бирү (мәдәният һәм сәнгать, шул исәптән музыка һәм сәнгать) оешмалары укытучылары, музыкаль һәм сәнгать гомуми белем бирү оешмаларының махсус дисциплиналары укытучылары, педагогика училищеларының (педагогика көллиятләренең) музыкаль дисциплиналары укытучылары, музыка укытучылары, музыка җитәкчеләре, концертмейстерлар.

6.4.6. Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазифаларында эшләү вакыты, әлеге вазифаларда эшләү чорында хезмәткәрнең педагогик белеме булса яки югары белем яки һөнәри белем бирү оешмасында укыса, педагогик эш стажына исәпләнә.

6.4.7. Оешма хезмәткәрләренең белем бирү оешмаларында төп эшеннән тыш башкарылган педагогик эш вакыты, сәгатьләп түләү шартларында аның күләме уку елында 180 сәгатьтән дә ким булмаса, педагогик стажга кертелә.

Шул ук вакытта педагогик стажга педагогик эш башкарган айлар гына кертелә.

6.4.8. Учреждениеләрдә, оешмаларда эшнең һәм Совет Социалистик Республикалар Союзы Кораллы Көчләрендә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәтнең укыту предметы (курс, дисциплина, түгәрәк) эш профиленә туры килүе турындагы конкрет мәсьәләләрне хәл итү хокукы, профсоюз органы белән килештереп, мәгариф оешмасы җитәкчесенә бирелә.

6.5. Медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм аларны билгеләү тәртибе.

6.5.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$), һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, аттестация нәтиҗәләре буенча тариф-квалификация характеристикалары нигезендә квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота торган белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – медицина хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

Dkk – 6 таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) әмере датасы нигезендә башкарыла.

6 таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Квалификация категориясе** | **Өстәмә түләүләр күләме, процент** |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче | 3,0 |
| Беренче | 6,0 |
| Югары | 10,0 |
| Табиб һәм провизор вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче | 6,0 |
| Беренче | 10,0 |
| Югары | 20,0 |

6.5.2. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – медицина хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирү өчен нигез булган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге нигезләмәгә кушымтаның 3 таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме булган медицина хезмәткәрләренә андый исемнәр булган өчен билгеләнән торган түләү, медицина хезмәткәре теләгенә нигезләнеп, мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

6.5.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) медицина хезмәткәрләренә, профиль буенча эш дәвамлылыгыннан һәм һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, стаж төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – медицина хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – 7 таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

7 таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме атамасы** | **Стаж буенча төркем** | **Өстәмә түләүләр күләме, процент** |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесендә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

6.6. Мәдәният хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм тәртибе.

6.6.1. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Мәдәният хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирү өчен нигез булган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 2 таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр күләме аларны биргән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре булган мәдәният хезмәткәрләренә андый исемнәр булган өчен билгеләнә торган түләү, мәдәният хезмәткәре теләгенә нигезләнеп, мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

6.6.2. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) мәдәният хезмәткәрләренә, профиль буенча эш дәвамлылыгыннан һәм һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, стаж төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи окладының;

$D_s$ – 8 таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

8 таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 0,75 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,0 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 1,25 |
| | 15 елдан артык | 1,75 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

6.7. Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм аларны билгеләү тәртибе.

6.7.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($В_{kk}$), һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, аттестация нәтиҗәләре буенча тариф-квалификация характеристикалары нигезендә квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота торган белгечлекләр буенча эшләүче авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ – 9 таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) әмере датасы нигезендә башкарыла.

9 таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| «Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифасы» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 5,0 |
| Югары | 8,0 |

6.7.2. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасындагы 5 таблицада китерелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме булган авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә мондый исемнәр булган өчен билгеләнә торган түләү, авыл хуҗалыгы хезмәткәре теләгенә нигезләнеп, мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

6.7.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, авыл хуҗалыгы буенча һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, стаж төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%}$$ ,

биредә:

$O_d$ – авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – 10 таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

10 таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме атамасы** | **Стаж буенча төркем** | **Өстәмә түләүләр күләме, процент** |
|---|---|---|
| Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 5 елга кадәр | 3,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | 15 елдан артык | 6,5 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

6.8. Премия һәм башка бүләкләү түләүләре төп эш урыны буенча муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә (укытучылар һәм укытучылар вазифасын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) юбилей даталары, аерым хөрмәт билгеләре, рәхмәт хатлары, мактаулы исемнәр алу белән бәйле рәвештә һәм локаль актлар һәм муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең коллектив шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер вакыт аралыгында (бер ай, квартал, ел) бер тапкыр билгеләнә.

6.8.1. Эш нәтиҗәләре буенча премия һәм башка бүләкләү түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең локаль актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

6.8.2. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә премия түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фонды күләме хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча окладлар (хезмәт хакы ставкалары, вазифаи окладлар), стимуллаштыру характерындагы түләүләр башкаруга каралган хезмәт өчен түләү фондының (укытучы вазифаларын биләүче хезмәткәрләрдән кала) кимендә 2 процентын тәшкил итә.

6.9. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә, төп эш урыны һәм төп вазифасыннан (укытучылар һәм укытучылар вазифасын биләгән хезмәткәрләрдән тыш) чыгып, билгеле бер вакыт аралыгындагы хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

6.9.1. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары күрсәткечләре һәм түләүләрне башкару шартлары муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе алдына куелган бурычлар нигезендә ел саен билгеләнә.

6.9.2. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләме, тәртибе һәм шартлары муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

6.9.3. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр ($B_{kj}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kj} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m}(I_{ij} x K_i)} x \sum_{i=1}^{n}(I_{ij} x K_i),$$

биредә:

$FOT_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүгә каралган хезмәткә түләү фонды;

$I_{ij}$ – j-хезмәткәр буенча эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-критерие;

$K_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүдәге i-критерийның чагыштырма үлчәү коэффициенты;

n – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m – муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре саны.

6.9.4. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле зурлыктагы нәтиҗәлелек критерийларын чагыштыруны тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткечләре диапазонын (иң яхшысын һәм иң начарын) сайлаудан гыйбарәт, шуларның берсе нормалаштырылган критерийның нульгә тигез күрсәткеченә, башкасы – бергә тигез күрсәткеченә туры килә. Нәтиҗәлелек критериенең факттагы күрсәткече эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткече диапазоны чикләрендә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие нульдән алып бергә кадәр билгеләнә. Нәтиҗәлелек критериенең факттагы күрсәткече иң начар күрсәткечтән түбәнрәк булганда, нормалаштырылган критерий күрсәткече – нульгә, иң яхшы билгедән югары булганда – бергә тигез була.

6.9.5. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерий күрсәткеченең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткеченә бәйле булуы турыдан-туры (уңай динамика критерий күрсәткече арту белән билгеләнә) һәм кире (уңай динамика критерий күрсәткече кимү белән билгеләнә) булырга мөмкин.

6.9.6. Нормалаштырылган критерий ($I_i$), аның күрсәткече критерий күрсәткеченә турыдан-туры бәйле булганда, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

биредә:

$FI_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериенең факттагы күрсәткече;

$M_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериенең иң югары күрсәткече;

$L_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериенең иң түбән күрсәткече.

6.9.7. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие ($I_i$) , аның күрсәткече критерий күрсәткеченнән турыдан-туры бәйле булмаганда, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

биредә:

$FI_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның факттагы күрсәткече;

$M_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң югары күрсәткече;

$L_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң түбән күрсәткече.

6.9.8. Үлчәү коэффициентлары белән эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериенең өстенлек дәрәҗәсе билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Чагыштырма үлчәү коэффициенты ($K_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

биредә:

$VK_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүдәге i-критерийның үлчәү коэффициенты.

6.9.9. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының чик күләме 11-15 таблицаларда күрсәтелгән.

11 таблица

**Физик культура хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| № т/б | Вазифа атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1. Беренче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме (1 төркем) | | | |
| 1.1 | Спорт залы буенча дежур | Беренче | 5 |
| 2. Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме (2 төркем) | | | |
| 2.1 | Спорт инструкторы | Беренче | 45 |
| 2.2 | Адаптив физик культура буенча инструктор | Беренче | 45 |
| 2.3 | Спортчы-инструктор | Беренче | 45 |
| 2.4 | Спорт техникасыннан файдалану һәм аны ремонтлау буенча техник | Беренче | 45 |

| №<br>т/б | Вазифа атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 2.5 | Адаптив физик культура буенча инструктор-методист | Икенче | 50 |
| 2.6 | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты | Икенче | 50 |
| 2.7 | Тренер | Икенче | 50 |
| 2.8 | Физкультура-спорт оешмалары өлкән инструктор-методисты | Өченче | 55 |

12 таблица

## Мәгариф хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| №<br>т/б | Вазифа атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1. Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 1.1 | Физик культура буенча инструктор | Беренче | 45 |
| 1.2 | Инструктор-методист | Икенче | 50 |
| 1.3 | Методист | Өченче | 55 |
| 1.4 | Өлкән инструктор-методист | Өченче | 55 |
| 2. Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 2.1 | Структур бүлекчә мөдире (башлыгы): кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчәләр (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләреннән тыш) | Беренче | 65 |

| № т/б | Вазифа атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 2.2 | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | Икенче | 70 |

13 таблица

**Медицина хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| № т/б | Вазифа атамасы | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.1 | Шәфкать туташы (медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 40 |
| 1.2 | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 40 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.3 | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 50 |
| 3. Табиблар һәм провизорлар вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1 | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 60 |

14 таблица

**Мәдәният хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары буенча**

**үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| № т/б | Вазифа атамасы | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1 | Билетлар контролеры | 5 |
| 2. Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1 | Билет кассалары мөдире | 35 |

15 таблица

**Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| № т/б | Вазифа атамасы | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. «Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифасы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.1 | Ветеринария табибы | 55 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.2 | Икенче категорияле ветеринария табибы | 60 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.3 | Беренче категорияле ветеринария табибы | 63 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.4 | Әйдәүче ветеринария табибы | 65 |
| 2. «Дүртенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифасы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.1 | Баш агроном | 70 |

6.9.10. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критерийлары һәм аларны үлчәү коэффициентлары муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре карамагында булган «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы эшләгән типлаштырылган критерийлар нигезендә раслана.

6.9.11. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләрендә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр фонды ($FOT_k$)төзелә, аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times \frac{D_k}{100\%},$$

биредә:

$FOT_{do}$ – муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең төп эш урыны буенча муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең вазифаи окладлары буенча хезмәт хакын түләү фонды;

Dk – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру сыйфатындагы түләүгә хезмәт өчен түләү фонды өлеше.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүгә хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең төп эш урыны буенча муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең вазифаи окладлары буенча хезмәт өчен түләү фондының 2 проценты күләмендә кабул ителә.

## VII. Компенсация характерындагы түләүләр

7.1. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләрендә компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр;

- нормаль шартларга туры килмәгән шартларда (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры

килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр.

7.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән һәм Казан шәһәренең физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

7.3. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

биредә:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең төп оклады күләме;

$D_{kh}$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган компенсация характерындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар буенча компенсация сыйфатындагы түләүләр билгеләү өчен нигез булып торган факттагы эшләгән вакыт (ставка);

$H_n$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең төп окладлы (хезмәт хакы ставкасы өчен) өчен сәгать нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү нормаль хезмәт шартларында төрле эшләр өчен билгеләнгән окладлар (вазифаи окладлар) белән чагыштырганда күбрәк күләмдә, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә кимендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

7.4. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) эш өчен түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

Хезмәткәрне график белән билгеләнгән ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп иткән очракта, вазифаи оклад алучы хезмәткәрләргә

эш өчен кимендә икеләтә күләмдә түләнә, шул ук вакытта ял көнендәге яки эш көне булмаган бәйрәм көнендәге эш хезмәт вакытының айлык нормасы чикләреннән арттырылмый башкарылган булса, окладтан тыш кимендә гадәти көнлек яки сәгатьлек төп ставка күләмендә түләнә, эш айлык нормадан арттырылып башкарылган булса, төп окладтан тыш кимендә икеләтә сәгатьлек яки көнлек ставка күләмендә түләнә.

7.5. Ял көннәрендә яки ял көнендә эшләгән хезмәткәр теләге белән аңа икенче ял көне бирелергә мөмкин. Бу очракта эш көне булмаган бәйрәм көнендәге хезмәт гадәти күләмдә түләнә, ә ял көне өчен түләнми.

## VIII. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчеләренең, җитәкче урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәт хакын билгеләү тәртибе

8.1. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт хакы вазифаи окладлардан, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән тора.

8.2. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе җитәкчесенең вазифаи окладьі ($O_b$) гамәлгә куючы тарафыннан, хезмәт өчен түләү төркеменә карап, агымдагы елның 1 гыйнварына яисә муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесен оештыру датасына бер тапкыр билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

биредә:

$O_b$ – җитәкченең төп окладьі күләме;

S – фактта эшләнгән вакыт (ставка).

Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе җитәкчесенең хезмәт хакы төркеме муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең штат санына карап билгеләнә.

8.3. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының вазифаи окладлары әлеге учреждениеләр җитәкчеләренең вазифаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

8.4. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт хакы һәм җитәкчеләрнең база оклады күләмнәре 16 таблицада күрсәтелгән.

16 таблица

**Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчеләренең төп окладлары күләмнәре**

| **Җитәкче хезмәте өчен түләү төркеме** | **Күләм күрсәткеченең әһәмияте (хезмәткәрләрнең штат саны), кеше** | **Төп оклад, сум** |
|---|---|---|
| 1 | 20 гә кадәр | 26 500 |
| 2 | 21-40 | 27 500 |
| 3 | 41-60 | 28 500 |
| 4 | 61 һәм аннан күбрәк | 29 000 |

8.5. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләрен гамәлгә куючы, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләргә мөмкин.

Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен эш нәтиҗәләре буенча ай саен башкарылырга мөмкин.

8.6. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе җитәкчесе, үз эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе җитәкчесе урынбасарларына, муниципаль учреждениенең баш бухгалтерына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләү билгеләргә мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләр мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен эш нәтиҗәләре буенча ай саен башкарылырга мөмкин.

8.7. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары һәм аларны үлчәү коэффициентлары карамагында муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре булган «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан Татарстан

Республикасы Спорт министрлыгы эшләгән типлаштырылган критерийлар нигезендә раслана.

8.8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр ($B_k$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_c \times K_{vk},$$

биредә:

$B_c$ – муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесенең җитәкчесе (җитәкче урынбасарлары, баш бухгалтер) окладының 10 проценты күләмендә кабул ителә торган стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме;

$K_{vk}$ – сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

8.9. Компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе җитәкчесе, җитәкче урынбасарлары, баш бухгалтеры өчен билгеләнә.

8.10. Финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан формалаштырыла һәм календарь ел өчен исәпләнә торган физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының айлык уртача хезмәт хакы һәм мондый учреждениеләр хезмәткәрләренең айлык уртача хезмәт хакы (тиешле җитәкченең, аның урынбасарларының, баш бухгалтерының хезмәт хакын исәпкә алмыйча) нисбәтенең чик дәрәҗәсе өч тапкыр артыграк күләмдә билгеләнә.

## IX. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

9.1. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарыннан, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саныннан чыгып билгеләнгән чаралар күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

9.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазифаи окладларны, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләү муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә (эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчесе гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен дә кертеп) финанс-хуҗалык

эшчәнлеге планында яисә муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесенең агымдагы бюджет сметасында хезмәт өчен түләүгә каралган акчалар исәбеннән башкарыла.

9.3. Тиешле чор өчен (ай, квартал, ел) финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары исәбеннән, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында килеп чыккан хезмәткә түләү фондын экономияләү чаралары муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү булганда, кызыксындыру түләүләре хезмәт өчен түләү фонды экономияләнгән вазифаларның һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә (эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен дә кертеп) бирелә.

Эш вакыты нормасын исәпкә алып, хезмәт нормаларын (хезмәт бурычларын) үтәгән муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәренә тиешле чорда хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә башкарылган кызыксындыру түләве күләме 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында»гы федераль закон белән билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән өч тапкыр артык була алмый (муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчеләреннән кала).

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбеннән муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчеләренә кызыксындыру түләүләре күләме «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан билгеләнә.

Финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр хисабыннан муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләүдән файдалану өчен җаваплылык муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчесенә йөкләнә.

__________________

Казан шәһәренең
муниципаль физик культура һәм
спорт учреждениеләре
хезмәткәрләре хезмәте өчен
түләү шартлары турында
нигезләмәгә
кушымта

1 таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә стимуллаштыру түләүләре биру өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм ведомство бүләкләре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем, спорт исеме<br>һәм ведомство бүләкләре |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Халык укытучысы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган укытучысы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган җитештерү буенча белем биру остасы |
| 1.6 | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.7 | Россиянең Атказанган спорт мастеры |
| 1.8 | Россиянең Атказанган тренеры |
| 1.9 | Россиянең Атказанган халыкара класслы спорт мастеры |
| 1.10 | Россиянең халыкара класслы спорт мастеры |
| 1.11 | Россия спорт мастеры |
| 1.12 | Россия гроссмейстеры |
| 1.13 | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| Совет Социалистик Республикалар Союзы (РСФСР)<br>мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 2.1 | СССРның Халык укытучысы |
| 2.2 | СССРның Атказанган спорт мастеры |
| 2.3 | СССРның Атказанган тренеры |

| № т/б | **Мактаулы исем, спорт исеме hәм ведомство бүләкләре** |
|---|---|
| 2.4 | СССРның спорт мастеры |
| 2.5 | СССРның халыкара масштаблы спорт мастеры |
| 2.6 | СССР гроссмейстеры |
| Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | Атказанган физкультура hәм спорт эшлеклесе |
| 3.2 | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 3.3 | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 3.4 | Атказанган физик культура hәм спорт хезмәткәре |
| 3.5 | Атказанган тренер |
| 3.6 | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 3.7 | Атказанган hөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 3.8 | Атказанган hөнәри-техник белем бирү остасы |
| 3.9 | Атказанган hөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 3.10 | Атказанган укытучы |
| 3.11 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.12 | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 3.13 | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 3.14 | Атказанган фән hәм техника эшлеклесе |
| 3.15 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган физкультура hәм спорт эшлеклесе |
| 4.2 | Атказанган физик культура hәм спорт хезмәткәре |
| 4.3 | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 4.4 | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.5 | Атказанган hөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 4.6 | Атказанган hөнәри-техник белем бирү остасы |
| 4.7 | Атказанган hөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.8 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.9 | Атказанган фән hәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.10 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.11 | Атказанган фән hәм техника эшлеклесе |
| 4.12 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4.13 | Атказанган тренер |
| 5. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Татарстан Республикасының Халык укытучысы |
| 5.2 | Татарстан Республикасының Атказанган мәктәп укытучысы |

| № т/б | **Мактаулы исем, спорт исеме<br>һәм ведомство бүләкләре** |
|---|---|
| 5.3 | Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы |
| 5.4 | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.5 | Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 5.6 | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 5.7 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.8 | Татарстан Республикасының Атказанган тренеры |
| Ведомство бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы<br>(Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.2 | Россия Федерациясенең башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3 | Россия Федерациясенең урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4 | Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6 | Россия Федерациясенең яшьләр сәясәте өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.7 | Россия Федерациясенең физик культура һәм спорт мактаулы хезмәткәре |
| 2. СССРның (РСФСР) Халык мәгарифе министрлыгы,<br>СССРның (РСФСР) Мәгариф министрлыгы | |
| 2.1 | «СССРның мәгариф отличнигы» билгесе |
| 2.2 | «Халык мәгарифе отличнигы» билгесе |
| 2.3 | «СССРның һөнәри техник белем бирү отличнигы» билгесе |
| 2.4 | «РСФСРның һөнәри техник белем бирү отличнигы» билгесе |
| 2.5 | «Физик культура һәм спорт отличнигы» билгесе |

2 таблица

**Мәдәният хезмәткәрләренә<br>стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен<br>нигез булып торган мактаулы исемнәр<br>исемлеге**

| № т/б | **Мактаулы исем атамасы** |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Халык артисты |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |

| № т/б | **Мактаулы исем атамасы** |
|---|---|
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган артисты |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Халык артисты |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Халык язучысы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының Халык шагыйре |
| 2.4 | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.5 | Татарстан Республикасының Атказанган артисты |
| 2.6 | Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССРның Халык артисты |
| 3.2 | СССРның Халык рәссамы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган пропагандачы |
| 4.2 | Халык артисты |
| 4.3 | Атказанган артист |
| 4.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.5 | Халык рәссамы |
| 4.6 | Атказанган рәссам |
| 4.7 | Халык язучысы |
| 4.8 | Атказанган язучы |
| 4.9 | Халык шагыйре |
| 4.10 | Халык җырчысы |

| № т/б | **Мактаулы исем атамасы** |
|---|---|
| 4.11 | Халык акыны |
| 4.12 | Атказанган журналист |
| 4.13 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14 | Атказанган мәдәни-мәгърифәтчелек эше хезмәткәре |
| 4.15 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.16 | Атказанган китапханәче |
| 4.17 | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.18 | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.19 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Халык артисты |
| 5.2 | Атказанган артист |
| 5.3 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.4 | Халык рәссамы |
| 5.5 | Атказанган рәссам |
| 5.6 | Халык язучысы |
| 5.7 | Атказанган язучы |
| 5.8 | Халык шагыйре |
| 5.9 | Атказанган журналист |
| 5.10 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.11 | Атказанган китапханәче |
| 5.12 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |

3 таблица

**Медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Атказанган табибы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Атказанган табибы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |

4 таблица

**Физик культура хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр, спорт исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем, спорт исеме исеме |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.2 | Россиянең Атказанган спорт мастеры |
| 1.3 | Россиянең Атказанган тренеры |
| 1.4 | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 1.5 | Россиянең Атказанган халыкара класслы спорт мастеры |
| 1.6 | Россиянең халыкара класслы спорт мастеры |
| 1.7 | Россия спорт мастеры |
| 1.8 | Россия гроссмейстеры |
| 1.9 | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Атказанган тренеры |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | ССРның Атказанган спорт мастеры |

| № т/б | Мактаулы исем, спорт исеме исеме |
|---|---|
| 3.2 | СССРның Атказанган тренеры |
| 3.3 | СССРның спорт мастеры |
| 3.4 | СССРның халыкара класслы спорт мастеры |
| 3.5 | СССРның Атказанган тренеры |
| 3.6 | СССР гроссмейстеры |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2 | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 4.3 | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 4.4 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.5 | Атказанган тренер |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 5.2 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |

5 таблица

**Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Атказанган агрономы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган ветеринария табибы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган зоотехнигы |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган мелиораторы |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 1.6 | Россия Федерациясенең Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Атказанган агрономы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе |
| 2.4 | Татарстан Республикасының Атказанган зоотехнигы |
| 2.5 | Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы |

| № т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 2.6 | Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 2.7 | Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССРның Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 4.2 | Атказанган агроном |
| 4.3 | Атказанган авыл хуҗалыгы инженеры |
| 4.4 | Атказанган зоотехник |
| 4.5 | Атказанган терлекчелек хезмәткәре |
| 4.6 | Атказанган терлекче |
| 4.7 | Атказанган терлекчелек остасы |
| 4.8 | Терлекчелек остасы |
| 4.9 | Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 4.10 | Атказанган механизатор |
| 4.11 | Атказанган мелиоратор |
| 4.12 | Атказанган ветеринария табибы |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 5.2 | Атказанган агроном |
| 5.3 | Атказанган зоотехник |
| 5.4 | Атказанган терлекче |
| 5.5 | Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 5.6 | Атказанган механизатор |
| 5.7 | Атказанган ветеринария табибы |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 27 августындагы
3589 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын гамәлгә кертә.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – төп окладлар, хезмәт хакының төп ставкалары, вазифаи окладлар күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне кертеп, муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад (вазифаи оклад) – компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, Казан шәһәренең муниципаль физик культура һәм спорт

учреждениесенең тиешле һөнәри квалификация төркеменә кергә торган эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы хезмәткәренең минималь оклады (вазифаи окладны);

- вазифаи оклад – компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, бер календарь ай дәвамында факт буенча эшләнгән вакыт эчендә билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе хезмәткәре хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәт өчен түләү) – муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе хезмәткәренең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына бәйле рәвештә, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре;

- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы, шул исәптән нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

- стимуллаштыру характерындагы түләүләр – стимуллаштыру характерындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе хезмәткәренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- вазифаи окладлардан;
- компенсация характерындагы түләүләр;
- стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләрдән.

## II. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре»<br>һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 242 |
| Икенче | 19 440 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре»<br>һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 581 |
| Икенче | 19 755 |
| Өченче | 19 933 |
| Дүртенче | 20 464 |

2.2. Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары»<br>һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 242 |
| Икенче | 19 440 |
| «Икенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары»<br>һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19 581 |
| Икенче | 19 755 |
| Өченче | 19 933 |
| Дүртенче | 20 160 |
| Бишенче | 20 346 |
| «Өченче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары»<br>һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 20 536 |
| Икенче | 20 729 |
| Өченче | 20 926 |
| Дүртенче | 21 127 |
| Бишенче | 21 353 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 22 265 |
| Икенче | 22 465 |
| Өченче | 22 665 |

2.3. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәре вазифасының һәм һөнәренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

2.4. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең өчен, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларындагы хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яисә башкарылган эш күләменә карап башкарыла. Төп вазифа буенча, шулай ук икенче вазифа буенча хезмәт хакы күләмнәре һәр вазифа буенча аерым билгеләнә.

## III. Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

Муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә;

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_n},$$

биредә:

$O_b$ – муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге буенча кабул ителә торган төп оклады күләме;

$H_f$ – Казан шәһәренең муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакыты дәвамлылыгы чикләрендә эш сәгатьләренең факттагы саны;

$H_n$ – Казан шәһәренең муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең төп оклады өчен сәгатьләр нормасы.

## IV. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәсенә стимуллаштыруга, шулай ук башкарган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;
- вазифа буенча эш стажы өчен түләүләр;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә түләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_b$ – Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме 3 процент тәшкил итә.

4.4. Хезмәткәрләргә тиешле түләүләр билгеләү өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге нигезләмәнең кушымтасында китерелгән.

4.5. Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исеме булган хезмәткәрләргә мондый исемнәр булган өчен бирелә торган түләү, хезмәткәр теләгенә нигезләнеп, берсе буенча билгеләнә.

4.6. Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вазифа (белгечлек) буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) вазифасы (белгечлеге) буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләренең төркемнәре буенча стажга карап билгеләнә һәм түбәндәге формула белән исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – вазифа (белгечлек) буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме.

4.7. Вазифа (белгечлек) буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме түбәндәгечә билгеләнә:

- вазифа (белгечлек) буенча эш стажы 2 дән 5 елга кадәр булганда – 2,5 процент;
- 5 елдан 10 елга кадәр – 4 процент;
- 10 елдан 15 елга кадәр – 5 процент;
- 15 елдан артык – 6 процент.

4.8. Эш стажы үзгәргәндә, вазифа (белгечлек) буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар оешмада булса, эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажны тутырган көннән алып, яки стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

4.9. Вазифа (белгечлек) буенча эш стажына 1 таблица нигезендә вазифалар (һөнәрләр) буенча эш вакыты керә.

1 таблица

**Эшләнгән вакыт**
**вазифа (белгечлек) буенча эш стажына**
**санала торган вазифалар (һөнәрләр)**
**исемлеге**

| N т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазифалары атамалары («баш», «өлкән» вазифаи атамаларны да кертеп, барлык эчке вазифа категорияләре) | Стимуллаштыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| 1 | Финанс бүлеге башлыгы, план-икътисад бүлеге башлыгы, баш бухгалтер урынбасары, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык хисабы һәм хуҗалык эшчәнлеге анализы буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәп) үзәге икътисадчысы, шартнамә һәм дәгъва эше буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча техник, хисапчы, калькулятор, кассир, таксировщик, статистик, хисапчы | Финанс бүлеге башлыгы, план-икътисад бүлеге башлыгы, баш бухгалтер урынбасары, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык хисабы һәм хуҗалык эшчәнлеге анализы буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәп) үзәге икътисадчысы, шартнамә һәм дәгъва эше буенча икътисадчы, матди-техник тәэминат буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, хезмәт буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, хисапчы, калькулятор, кассир, таксировщик, статистик, хисапчы, салымнар һәм җыемнар буенча консультант, аудитор |
| 2 | Матди-техник яктан тәэмин итү буенча икътисадчы | Матди-техник тәэмин итү буенча икътисадчы, матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, склад мөдире, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык хисабы һәм хуҗалык эшчәнлеге анализы буенча икътисадчы, хисаплау (мәгълүмат-хисап) үзәге икътисадчысы, килешү һәм дәгъва эше буенча икътисадчы, |

| N т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазифалары атамалары («баш», «өлкән» вазифаи атамаларны да кертеп, барлык эчке вазифа категорияләре) | Стимуллаштыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | | планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, товар өчен җаваплы белгеч, планлаштыру буенча техник, хисапчы, таксировщик, хисапчы |
| 3 | Оештыру һәм хезмәт өчен түләү бүлеге башлыгы | Хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, социаль үсеш бүлеге башлыгы, хезмәт буенча икътисадчы, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, инструктор-дактилолог, хезмәт буенча техник, социолог, нарядчы, хронометражист |
| 4 | Хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча инженер | Хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү буенча лаборатория (бюро) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы инженеры, инженер |
| 5 | Кадрлар бүлеге (махсус бүлек һәм башкалар) башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, | Кадрлар бүлеге (махсус бүлек һәм башкалар) башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, кадрлар |

| N т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазифалары атамалары («баш», «өлкән» вазифаи атамаларны да кертеп, барлык эчке вазифа категорияләре) | Стимуллаштыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | кадрлар буенча инспектор, кадрлар әзерләү буенча инженер | әзерләү буенча инженер, инструктор-дактилолог, профконсультант, юрисконсульт, табельче |
| 6 | Социаль үсеш бүлеге башлыгы | Социаль үсеш бүлеге башлыгы, кадрлар бүлеге башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюро) башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, инструктор-дактилолог, кадрлар буенча инспектор, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы инженеры, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, хезмәт буенча техник, социолог |
| 7 | Профконсультант | Профконсультант, кадрлар бүлеге башлыгы, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, персонал буенча менеджер, психолог, социолог, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге инспекторы, инструктор-дактилолог |
| 8 | Юридик бүлек башлыгы, юрисконсульт | Юридик бүлек башлыгы, юрисконсульт |
| 9 | Архив мөдире, канцелярия мөдире, документлар белән эшләүче белгеч, архивариус, эш башкаручы, йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту буенча инспектор, сәркатип, машинкада бастыручы сәркатип, сәркатип-стенографист, күрү сәләтен югалткан белгеч сәркатибе, җитәкче сәркатибе, экспедитор | Архив мөдире, канцелярия мөдире, документлар белән эшләүче белгеч, архивариус, эш башкаручы, йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту буенча инспектор, сәркатип, машинкада бастыручы сәркатип, сәркатип-стенографист, күрү сәләтен югалткан белгеч сәркатибе, җитәкче сәркатибе, паспортчы, кодификатор, экспедитор |

| N т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазифалары атамалары («баш», «өлкән» вазифаи атамаларны да кертеп, барлык эчке вазифа категорияләре) | Стимуллаштыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| 10 | Машинкада бастыру бюросы мөдире, күчермәләр-нөсхәләр ясау бюросы мөдире, машинкада бастыручы | Машинкада бастыру бюросы мөдире, күчермәләр-нөсхәләр ясау бюросы мөдире, машинкада бастыручы, машинкада бастыручы сәркатип, күчермәләр ясаучы белгеч |
| 11 | Матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире | Матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире, товар белгече, агент, сатып алулар агенты, тәэмин итү буенча агент, тәэмин итү буенча икътисадчы, товар белгече, йөкләр ташу буенча экспедитор |
| 12 | Тулай торак мөдире, пропусклар бюросы дежуры, комендант, администратор | Пансионатның (кунакханәнең) торак корпусы мөдире, тулай торак мөдире, пропусклар бюросы мөдире, ял бүлмәсе мөдире, хуҗалык мөдире, пропусклар бюросы дежуры, белешмәләр бирү, кунакханә залы, автомобиль йөртүчеләрнең ял итү бүлмәсе, тулай торак һәм башкалар буенча дежур, комендант, администратор, саклау камерасы мөдире |
| 13 | Гараж башлыгы | Гараж башлыгы, автоколонна башлыгы, пассажир транспорты контролеры, диспетчерлык хәрәкәте һәм төяү-бушату эшләре операторы, автотехник экспертиза буенча белгеч (эксперт-автотехник), юл хуҗалыгы эксперты, автотранспорт йөртүчесе |
| 14 | Җитештерү мөдире (шеф-пешекче), ашханә мөдире | Җитештерү мөдире (шеф-пешекче), ашханә мөдире, пешекче |
| 15 | Диспетчер, диспетчерлык хезмәте операторы | Диспетчер, диспетчерлык хезмәте операторы, диспетчерлык хәрәкәте һәм төяү-бушату эшләре операторы |
| 16 | Фотолаборатория мөдире | Фотолаборатория мөдире, фотограф, рәссам-фотограф |

| N т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазифалары атамалары («баш», «өлкән» вазифаи атамаларны да кертеп, барлык эчке вазифа категорияләре) | Стимуллаштыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| 17 | Механик, ремонт буенча инженер, инженер-энергетик (энергетик) | Ремонт цехы башлыгы, остаханә башлыгы (мөдире), механик, ремонт буенча инженер, инженер-энергетик (энергетик), инженер |
| 18 | Инженер-программачы (программачы), техник-программачы, математик, фонд инспекторы, фонд инспекторы ассистенты | Җитештерү белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы бүлеге башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, инженер-программачы (программачы), җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру буенча инженер, җитештерү белән идарә итүнең автоматлаштырылган системалары буенча инженер, инженер, математик, техник-программачы, техник, фонд инспекторы, фонд инспекторы ассистенты |
| 19 | Фәнни-техник китапханә мөдире, мәгълүмат бүлеге башлыгы, мәгълүматны саклау бүлеге (лаборатория, сектор) башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча белгеч, мәгълүматны саклау буенча техник | Фәнни-техник китапханә мөдире, мәгълүмат бүлеге башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат бүлеге башлыгы, мәгълүматны саклау бүлеге (лаборатория, сектор) башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча инженер, патент һәм уйлап табу эше буенча инженер, инженер, мәгълүматны саклау буенча белгеч, мәгълүматны саклау буенча техник, техник |
| 20 | Техник-икътисади тикшеренүләр лабораториясе (бюросы) башлыгы, тикшеренү лабораториясе башлыгы, мәгълүмат бүлеге башлыгы, аналитик | Техник-икътисади тикшеренүләр лабораториясе (бюросы) башлыгы, тикшеренү лабораториясе башлыгы, мәгълүмат бүлеге башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат бүлеге башлыгы, аналитик |
| 21 | Инженер-лаборант, техник-лаборант, лаборант | Заводның үзәк лабораториясе башлыгы, җитештерү лабораториясе |

| N т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазифалары атамалары («баш», «өлкән» вазифаи атамаларны да кертеп, барлык эчке вазифа категорияләре) | Стимуллаштыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | | (җитештерүне контрольдә тоту буенча) башлыгы, инженер-лаборант, инженер, техник-лаборант, техник, лаборант |
| 22 | Инструмент буенча техник, техник-технолог | Җитештерү бүлеге башлыгы, техник бүлек башлыгы, сынау җитештерүе цехы башлыгы, инструменталь бүлек башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, җиһазларны туплау бүлеге башлыгы, цех (участок) башлыгы, (участок, цех) контроль остасы, участок остасы, инженер, җитештерүне әзерләү буенча инженер, инженер-технолог, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру буенча инженер, инструмент буенча инженер, җиһазларны туплау буенча инженер, инженер-конструктор, җитештерү белән идарә итүне оештыру буенча инженер, патент һәм уйлап табу эше буенча инженер, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, механик, техник, техник-конструктор, инструмент буенча техник, техник-технолог |
| 23 | Инженер | Барлык атамадагы инженер, җитештерү бүлеге башлыгы, техник бүлек башлыгы, сынау җитештерүе цехы башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, цех (участок) башлыгы, капиталь төзелеш бүлеге башлыгы, участок остасы, механик, техник, техник-конструктор, инструмент буенча техник, техник-технолог |

| N т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазифалары атамалары («баш», «өлкән» вазифаи атамаларны да кертеп, барлык эчке вазифа категорияләре) | Стимуллаштыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| 24 | Инженер-электроник (электроник), исәпләү (мәгълүмат-исәп) үзәге техникы | Инженер-электроник (электроник), исәпләү (мәгълүмат-хисап) үзәге техникы, инженер, инженер-программист (программист), техник-программачы, техник |
| 25 | Күчермә ясаучы белгеч | Сызымчы, сызымчы-конструктор, күчермәләр ясаучы белгеч, рәссам |
| 26 | Психолог | Психолог, медицина психологы, педагог-психолог, профконсультант |
| 27 | Физиолог | Физиолог, биолог |
| 28 | Социолог | Социолог, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы |
| 29 | Рәссам | Барлык атамалардагы рәссамнар, архитектор, сызымчы |
| 30 | Архитектор | Рәссам-конструктор (дизайнер), сызымчы-конструктор, сызымчы |
| 31 | Тәрҗемәче-дактилолог, сурдотәрҗемәче | Тәрҗемәче-дактилолог, сурдотәрҗемәче |
| 32 | Бүлек (ферма, авыл хуҗалыгы участогы) белән идарә итүче | Бүлек (ферма, авыл хуҗалыгы участогы) белән идарә итүче, агроном, зоотехник |
| 33 | Башка аерымланган структур бүлекчә филиалы директоры (башлыгы, мөдире) | Тиешле төрдәге икътисади эшчәнлек хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә кертелгән вазифалар |

4.10. Хезмәткәрләргә премия һәм башка бүләкләү түләүләре билгеле бер вакыт аралыгы (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук юбилей даталары, аерым хөрмәт билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, бүләкләр алуга бәйле рәвештә бер тапкыр һәм муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең локаль норматив актларында һәм коллектив килешүләрендә күрсәтелгән башка нигезләрдә билгеләнә.

4.11. Премияләр һәм башка бүләкләү түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.12. Эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә премия түләүләренә каралган хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме хезмәткәрләргә окладлар (вазифаи окладлар) түләүгә һәм төп эш урыны буенча стимуллаштыру характерындагы башка түләүләргә каралган хезмәт өчен түләү фондының кимендә 2 процентын тәшкил итә.

## V. Компенсация характерындагы түләүләр

5.1. Казан шәһәренең муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләрендә компенсация характерындагы түләүгә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр;
- нормаль шартларга туры килмәгән шартларда (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр.

5.2. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр һәм нормаль шартларга туры килмәгән шартларда (һөнәрләрне (вазифаларны) берләштерү, эш сәгатеннән тыш, төнлә эшләү, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү, эш күләмен арттыру яки хезмәт килешүе белән билгеләнгән эштән азат ителмәгән килеш вакытлыча эштән азат ителгән хезмәткәр вазифаларын үтәү, ял көннәрендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә эшләү) эшләгән өчен тиешле финанс елына Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фонды законнары нигезендә һәм расланган фонд чикләрендә билгеләнә.

Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар, әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.

5.3. Компенсация сыйфатындагы түләүләр ($В_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

биредә:

$O_b$ – Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп оклады;

$D_{kh}$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган компенсация сыйфатындагы өстәмә түләүләр күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация характерындагы түләүләр карала торган фактта эшләнгән вакыт;

$H_n$ – эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының төп хезмәт хакы ставкасы (төп окладь) өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган сәгатьләр нормасы.

Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен эш өчен түләүләр түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

- төнлә эшләүнең һәр сәгате өчен нормаль шартларда эшләү белән чагыштырганда артыграк күләмдә, әмма хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән күләмнәрдән кимрәк булмаган күләмдә түләнә;

- хезмәткәрне график буенча билгеләнгән ял көнендә яисә эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп иткән очракта, эш өчен кимендә икеләтә күләмдә түләнә;

- вазифаи оклад алучы хезмәткәрләргә – ял көнендәге яки эш көне булмаган бәйрәм көнендәге эш айлык эш вакыты нормасы чикләрендә башкарылган булса, окладтан тыш кимендә бер көнлек яки сәгатьлек төп ставка күләмендә һәм, эш айлык нормадан артык башкарылган булса, төп окладтан тыш кимендә икеләтә көнлек яки сәгатьлек ставка күләмендә;

- ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәргә, аның теләге буенча, икенче ял көне бирелергә мөмкин. Бу очракта эш көне булмаган бәйрәм көнендәге хезмәт гадәти күләмдә түләнә, ә ял көне өчен түләнми.

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү нормаль хезмәт шартларында төрле эшләр

өчен билгеләнгән окладлар (вазифаи окладлар) белән чагыштырганда күбрәк күләмдә, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә кимендә 4 процент күләмендә билгеләнә;

- һөнәрләрне (вазифаларны) берләштереп үтәгәндә, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткәндә, эш күләмен арттырганда яки хезмәт килешүендә билгеләнгән эштән азат ителмәгән килеш эштән вакытлыча азат ителгән хезмәткәр вазифаларын үтәгәндә, өстәмә эшнең эчтәлеген һәм (яки) күләмен исәпкә алып, хезмәт килешүен төзегән вәкилләрнең килешүе буенча билгеләнә торган күләмдә хезмәткәргә өстәмә түләнә.

---

Казан шәһәре муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта

1 таблица

**Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган архитекторы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган җир төзүчесе |
| 1.6 | Россия Федерациясенең Атказанган зоотехнигы |
| 1.7 | Россия Федерациясенең Атказанган уйлап табучысы |
| 1.8 | Россия Федерациясенең Атказанган конструкторы |
| 1.9 | Россия Федерациясенең Атказанган җитештерү буенча белем бирү остасы |
| 1.10 | Россия Федерациясенең Атказанган машина төзүчесе |
| 1.11 | Россия Федерациясенең Атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 1.12 | Россия Федерациясенең Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 1.13 | Россия Федерациясенең Атказанган азык-төлек индустриясе хезмәткәре |
| 1.14 | Россия Федерациясенең Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 1.15 | Россия Федерациясенең Атказанган текстиль һәм җиңел сәнәгать хезмәткәре |
| 1.16 | Россия Федерациясенең Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 1.17 | Россия Федерациясенең Атказанган рационализаторы |
| 1.18 | Россия Федерациясенең Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре |
| 1.19 | Россия Федерациясенең Атказанган коткаручысы |
| 1.20 | Россия Федерациясенең Атказанган төзүчесе |

| № т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 1.21 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 1.22 | Россия Федерациясенең Атказанган икътисадчысы |
| 1.23 | Россия Федерациясенең Атказанган энергетигы |
| 1.24 | Россия Федерациясенең Атказанган юристы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Халык укытучысы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы |
| 2.4 | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 2.5 | Татарстан Республикасының Атказанган уйлап табучысы |
| 2.6 | Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе |
| 2.7 | Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 2.8 | Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 2.9 | Татарстан Республикасының Атказанган җиңел сәнәгать хезмәткәре |
| 2.10 | Татарстан Республикасының Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре |
| 2.11 | Татарстан Республикасының Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 2.12 | Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 2.13 | Татарстан Республикасының Атказанган рационализаторы |
| 2.14 | Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре |
| 2.15 | Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы |
| 2.16 | Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе |
| 2.17 | Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы |
| 2.18 | Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы |
| 2.19 | Татарстан Республикасының Атказанган юристы |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССРның Халык архитекторы |
| 3.2 | СССРның Атказанган уйлап табучысы |
| 3.3 | СССРның Атказанган сәнәгать хезмәткәре |
| 3.4 | СССРның Атказанган төзүчесе |
| 3.5 | СССРның Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 3.6 | СССРның Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 3.7 | СССР Кораллы Көчләренең Атказанган белгече |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган сәнәгать хезмәткәре |
| 4.2 | Атказанган энергетик |
| 4.3 | Атказанган машина төзүче |
| 4.4 | Атказанган азык-төлек индустриясе хезмәткәре |
| 4.5 | Атказанган полиграфист |
| 4.6 | Атказанган транспорт хезмәткәре |

| № т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 4.7 | Атказанган автотранспорт хезмәткәре |
| 4.8 | Атказанган элемтәче |
| 4.9 | Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 4.10 | Атказанган төзүче |
| 4.11 | Атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 4.12 | Атказанган көнкүреш хезмәте хезмәткәре |
| 4.13 | Атказанган коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 4.14 | Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 4.15 | Атказанган халыкка коммуналь һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 4.16 | Атказанган коммуналь-көнкүреш хезмәте хезмәткәре |
| 4.17 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.18 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4.19 | Атказанган юрист |
| 4.20 | Атказанган инженер |
| 4.21 | Атказанган уйлап табучы |
| 4.22 | Атказанган рационализатор |
| 4.23 | Атказанган оста |
| 4.24 | Атказанган икътисадчы |
| 4.25 | Атказанган бухгалтер |
| 4.26 | Атказанган (эшләүче, эшче) яшьләр остазы |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган сәнәгать хезмәткәре |
| 5.2 | Атказанган машина төзүче |
| 5.3 | Атказанган медицина сәнәгате хезмәткәре |
| 5.4 | Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 5.5 | Атказанган шофер |
| 5.6 | Атказанган машина йөртүче |
| 5.7 | Атказанган элемтәче |
| 5.8 | Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 5.9 | Атказанган төзүче |
| 5.10 | Атказанган сәүдә һәм җәмәгать туклануы хезмәткәре |
| 5.11 | Атказанган сәүдә хезмәткәре |
| 5.12 | Атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 5.13 | Атказанган көнкүреш хезмәте хезмәткәре |
| 5.14 | Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 5.15 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.16 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.17 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.18 | Атказанган юрист |
| 5.19 | Атказанган милиция хезмәткәре |

| № т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 5.20 | Атказанган техник |
| 5.21 | Атказанган инженер |
| 5.22 | Атказанган уйлап табучы |
| 5.23 | Атказанган рационализатор |
| 5.24 | Атказанган икътисадчы |
| 5.25 | Атказанган бухгалтер |
| 5.26 | Атказанган халык хуҗалыгы хезмәткәре |
| 5.27 | Атказанган рационализатор һәм уйлап табучы |